РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«22» сентябрь, 2025 Олы Кайбыч ав. №4

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итү турында

«Гавами хакимият бердәм системасында җирле үзидарәне оештыру гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьеясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставының 47 статьясы нигезендә, Кайбыч муниципаль районы Советы вәкаләтләре чоры тәмамлану сәбәпле, Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең вәкаләтләре туктатылуга бәйле рәвештә, Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучылардан конкурска документлар кабул итүне 2025 елның 26 сентябреннән 2025 елның 16 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар урамы, 7 йорт, 304 бүлмә (Иҗтимагый үзәк бинасы) адресы буенча, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән кала, көн саен 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр башкарырга, тел.2-11-85.

2. Конкурс комиссиясенә 2025 елның 17 октябрендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы Бульвар ур., 7 йорт, 304 бүлмә адресы буенча Иҗтимагый үзәк бинасында «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2015 елның 21 августындагы 291 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә Конкурс үткәрергә, һәм конкурс нәтиҗәләрен һәм кандидатлар турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советына тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссиясенең 6 кешедән торган составын расларга.

4. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссиясенең 3 кешедән торган ярты составын кушымта нигезендә расларга.

5. Әлеге карарны «Кайбыч таңнары» газетасында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылыкны һәм хокук тәртибен үтәү буенча Кайбыч муниципаль районы Советының даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгы А.И. Рәхмәтуллин

Кайбыч муниципаль районы
Советының
2025 е. 22 сентябрендәге
__4__ номерлы карарына
кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ ВАЗЫЙФАСЫН БИЛӘҮГӘ КАНДИДАТУРАЛАРНЫ КАРАУ ӨЧЕН КОНКУРС КОМИССИЯСЕНЕҢ ЯРТЫСЫ

1. Лазарев Сергей Владимирович – «Рус Бәрлебашы төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры, Ябалак авыл җирлеге депутаты
2. Тараканов Петр Петрович - Мәлки авыл кулланучылар җәмгыяте советы рәисе, Чүти авыл җирлеге депутаты
3. Иванов Александр Александрович – «Август-Кайбицы» ҖЧҖ генераль директоры (килешү буенча).